Министерство образования и науки Республики Татарстан
Государственное автономное профессиональное образовательное учреждение
«Актанышский технологический техникум»

УТВЕРЖДАЮ:
директор ГАПОУ «АТТ»
_________ Л.Я. Шамсунова
« 26 » августа 20 22 г.

**КОНТРОЛЬНО-ОЦЕНОЧНЫЕ СРЕДСТВА ПО УЧЕБНОЙ ДИСЦИПЛИНЫ**

ОГСЭ.06. **«Татарский язык в профессиональной деятельности»**

09.02.07 ИНФОРМАЦИОННЫЕ СИСТЕМЫ И ПРОГРАММИРОВАНИЕ
код и наименование специальности

**Актаныш**
**2022**

# Эчтәлек

бит


1. **Студент нәрсә белергә һәм нәрсә эшли белергә тиеш** **5**
2. **Контроль билге кую - тикшерү–бәяләү төрләре һәм алымнары** **6 - 19**
3. **Кулланылган әдәбият** **20**
4. **Студентларнын белемнәрен бәяләү** **21 - 24**

Бу тикшерү – бәяләү алымнары **Мәгълүмати системалар һәм программалаштыру белгечлеге** өчен төзелде (022 ис)

Мәҗбүри уку дәресе - 72 сәгать

**Йомгаклау аттестациясе** – дифзачет

***Һөнәри эшчәнлектә татар теле фәнен үзләштергәннән соң студент белергә тиеш:***

Фонетик һәм орфоэпик принципларны, орфографик һәм грамматик кагыйдәләрне дөрес итеп урынлы куллана белергә; җөмләгә билгеләмә бирергә, әйтелешләре ягыннан җөмлә төрләрен, җөмләнең баш кисәкләрен, җөмләнең иярчен кисәкләрен, җыйнак һәм җәенке җөмләләрне аера белергә. Ияртүле һәм тезүле бәйләнешне аера белергә . Татар теленең сүз байлыгын барлап, аңа характеристика бирергә. Сүзләрнең һәм фразеологик әйтелмәләрнең лексик мәгънәләрен аңлатырга, аларга синоним омоним, антонимнар табарга. Бер һәм күп мәгънәле сүзләрне аера белергә. Аңлатмалы, энциклопедик, этимологик, тәрҗемәле сүзлекләр белән эшләргә. Татар клавиатураларын, сөйләм үзенчәлекләрен, сөйләм техникасын, стильләрне, эш кәгазьләре төрләрен белергә.
***Эшләргә тиеш***: Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен аерырга. Җөмләләрдә тыныш билгеләрен дөрес куярга. Чиста һәм орфография кагыйдәләрен дөрес кулланып язарга, үз фикерләрен сөйләм һәм язма формаларда логик яктан эзлекле, төгәл һәм җыйнак итеп биреп эшләргә тиеш.

Татар теленең сүз байлыгын барларга, аңа характеристика бирергә. Сүзләрнең һәм фразеологик әйтелмәләрнең лексик мәгънәләрен аңлатырга, аларга синоним, омоним, антонимнар табарга. Бер һәм күп мәгънәле сүзләрне аера белергә. Аңлатмалы, энциклопедик, этимологик, тәрҗемәле сүзлекләр белән эшләргә. Сөйләм техникасын, стильләрне, эш кәгазьләрен яза белергә.

## **Дифзачет өчен тест биремнәре.** II курс
## 1 НЧЕ ВАРИАНТ

### 1 нче өлеш - А

***Бу өлештәге биремнәрне (А 1—А 10) үтәгәндә, җавап сайлап алына  һәм үзегез сайлаган җавапның номерын А 1 дисез дә язып куясыз.***

**А 1. [ү] авазы ...**

1) югары күтәрелешле, иренләшкән, алгы рәт сузыгы
2) югары күтәрелешле, иренләшкән, арткы рәт сузыгы
3) югары күтәрелешле, иренләшмәгән, арткы рәт сузыгы
4) урта күтәрелешле, иренләшмәгән, алгы рәт сузыгы

**А 2. Кайсы рәттәге барлык сүзләрнең әйтелеше белән язылышы туры килә?**

1) тәрәзә, бала, кызык, кисмәк, сөрмәле
2) конгресс, вәгазь, төсле, котылгысыз
3) тозсыз, төнбоек, сәлам, гайрәт
4) хәрабә, койрык, көзге, галәм

**А 3. Кайсы рәттәге сүзләрнең барысы да дүртәр аваздан тора?**

1) иман, аяк, иҗат, буя, уяу
2) гаять, дага, дала, ярау
3) дөя, елау, ешаю, икәү
4) еру, ефәк, изге, илле

**А 4.** ***Алмыйсыңдыр*** **сүзенең мәгънәле кисәкләргә дөрес бүленешен күрсәтегез.**

1) ал-мый-сың-дыр
2) ал-мы-й-сың-ды-р
3) ал-ма-ый-сың-дыр
4) ал-ма-й-сың-дыр

**А 5.** *Байлыгы белән мактану* **сүзтезмәсендә компонентларны үзара бәйләүче чараны күрсәтегез.**

1) янәшә тору
2) тартым кушымчасы
3) бәйлек
4) тезүче теркәгеч

**А 6. Җөмләдә сүзләр ...**

1) тезүле бәйләнештә генә була
2) тезүле һәм ияртүле бәйләнештә була
3) ияртүле бәйләнештә генә була
4) янәшә торып кына бәйләнә ала

**А 7. Җөмләдә ничә компонент бар, алар үзара ничек бәйләнгән? Җөмләнең төрен билгеләгез.**

***Мин беләгемне ычкындырмакчы булып карадым — көчем җитмәде.*** *(Ә. Еники)*

1) ике, санау интонациясе ярдәмендә бәйләнгәннәр, бу — теркәгечле тезмә кушма җөмлә
2) ике, санау интонациясе ярдәмендә бәйләнгәннәр, бу — теркәгечсез тезмә кушма җөмлә
3) ике, каршы кую интонациясе ярдәмендә бәйләнгәннәр, бу — теркәгечсез тезмә кушма җөмлә
4) ике, көттерү интонациясе ярдәмендә бәйләнгәннәр, бу — иярченле кушма җөмлә

**А 8.** ***Сезнең кебек без дә бишәү идек.*** *(Х.Әюпов)* Бу җөмләдәге ***бишәү*** сүзе җөмләнең кайсы кисәге?

1) аныклагыч
2) аергыч
3) кушма хәбәр составында
4) күләм хәле
4) гади җөмләләре икедән артык җөмлә

**А 9. Кушма җөмлә ул — ...**

1) бер яки ике хәбәрлеге булган җөмлә
2) ике яки икедән артык хәбәрлеге булган җөмлә
3) бер генә хәбәрлеге булган җөмлә
4) бер яки берничә хәбәрлеге булган җөмлә

**А 10. Тыныш билгесе кайсы очракта дөрес куелган?**

***Икесенең дә сүз әйтерлек хәлләре калмаган (1) күзләре генә көлә дә*** *(2)* ***иреннәре елмая иде*** *(3) (Л. Ихсанова)*

1) (1) өтер, (2) тыныш билгесе куелмый, (3) нокта
2) (1) өтер, (2) өтер, (3) нокта
3) (1) өтер, (2) нокталы өтер, (3) нокта *
4) (1) нокталы өтер, (2) өтер, (3) нокта

**А 11. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләр җөмләнең кайсы кисәге икәнен күрсәтегез.**

*Моннан поездлар* ***төрле тарафка*** *йөри. (Ә. Галиев)*

1) тәмамлык
2) урын хәле
3) күләм хәле
4) аергыч

**А 12. Бирелгән өзек нинди стильдә язылган?**

(1) Без яшәгән көннәр каядыр китеп югала. (2) Алар урынына без көткән киләчәк килә тора. (3) Вакыт һәрнәрсәне үзгәртә. (4) Киләчәк, бүгенгегә әйләнгәч, ни өчендер, без көткән тылсымлылыгын югалта, гадиләнә, тоныклана төшә. (5) Артта калган көннәр инде синеке түгел, алдагы көннәр, исән булсак, безнеке. (6) Көч бар чакта, эшлисе эшне эшләп, яулыйсы позицияләрне яулап калырга кирәк. (7) Картая башлагач, хыялыңа ияреп, диңгезгә чыгып китә алмассың.

1) публицистик стильдә
2) матур әдәбият стилендә
3) рәсми стильдә
4) фәнни стильдә

**2 нче өлеш -** В

***Бу өлештәге биремнәрне үтәгәндә, сорау янына ничә сан куела, җаваплар шул хәтле булырга тиеш.***

1. Татарстан республикасындагы дәүләт телләре (1, 2)
2. Татар сүзләрендә генә кулланыла торган хәрефләр (1, 2, 3, 4, 5, 6)
3. Төрки халыкларда (татарларда) кулланылган язулар (хәрефләр, ягъни графикалар) (1, 2, 3, 4, 5)
4. Алмашлык төркемнәрен санарга (1, 2, 3, 4, 5, 6, 7)
5. Җөмләнең модаль кисәкләре (1, 2)
6. Кушма җөмләләрнең төрләре (1, 2)

**3 нче өлеш –** С 1

***Текстны укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.***

1) Әйе, бу җирдә кечкенә генә, җыйнак кына бер дача – авыл бар иде. 2) Без – мәк чәчәкләре, гөлчәчәкләр, исле сиреньнәр, шомыртлар, алмагачлар, кура җиләкләре – аның ямьле бизәкләре, тәмле җимешләре идек. 3) Менә бу чокыр урынында исә без, мәк чәчәкләре, кайчандыр зур түгәрәк бер түтәл булып үсеп утыра идек... 4) Безнең нәкъ уртабызга ул, - көнбатыштан килгән ерткыч вәхши, - авыр бомба ташлады. 5) Без янартау авызыннан атылган утлы туфрак һәм көл булып һавага ыргылдык. 6) Бу күз ачып йомганчы булды... 7) Тетрәп киткәндәй күренгән кояш та яңадан, бернәрсә дә булмагандай, балкый иде. 8) Мин – бердәнбер мәк орлыгы – кире үз урыныма, менә шушы чокыр төбенә очып төшкәнмен.

1) Тексттан синонимнар булган җөмләне табып, санын күрсәтегез.
2) 4 – 7 җөмләләрдән фразеологик әйтелмәләрне язып алыгыз.
3) 1 – 2 җөмләләрдән кушма һәм тезмә җөмләләрне язып алыгыз.
4) 6 – 8 җөмләләрдән алмашлыкларны язып алыгыз, мәгънәви төркемнәрен билгеләгез.
5) 2, 3 нче җөмләләрдәге *мәк чәчәкләре* сүзенең синтаксик вазыйфасын билгеләгез.

**3 нче өлеш –** С 2

"Минем киләчәк һөнәрем" дигән темага миниатюр сочинение язарга.

***Җаваплар:***

**1 нче өлеш**

| | |
|---|---|
| **А 1** | **1** |
| **А 2** | **1** |
| **А 3** | **1** |
| **А 4** | **3** |
| **А 5** | **3** |
| **А 6** | **2** |
| **А 7** | **3** |
| **А 8** | **3** |
| **А 9** | **2** |
| **А 10** | **2** |
| **А 11** | **2** |
| **А 12** | **2** |

**2 нче өлеш**

1. Татарстан республикасындагы дәүләт телләре (татар, рус)
2. Татар сүзләрендә генә кулланыла торган хәрефләр (ә, ө, ү, ж, ң, һ)
3. Төрки халыкларда (татарларда) кулланылган язулар (хәрефләр, ягъни графикалар) (рун, уйгур, гарәп, латин, кириллица)
4. Алмашлык төркемнәрен санарга (зат, күрсәтү, сорау, билгеләү, билгесезлек, тартым, юклык)
5. Җөмләнең модаль кисәкләре (эндәш сүзләр, кереш сүзләр)
6. Кушма җөмләләрнең төрләре (иярченле кушма җөмләләр, тезмә кушма җөмләләр)

**3 нче өлеш**

1. 1
2. Күз ачып йомганчы
3. Мәк чәчәкләре, гөлчәчәкләр, алмагачлар, кура җиләкләре
4. Бу – күрсәтү алмашлыгы, бернәрсә – юклык алмашлыгы, мин – зат алмашлыгы, үз – билгеләү алмашлыгы, менә – күрсәтү алмашлыгы, шушы – күрсәтү алмашлыгы
5. Аныклагыч

**2 НЧЕ ВАРИАНТ**
**1 нче өлеш - А**

***Бу өлештәге биремнәрне (А 1—А 10) үтәгәндә, җавап сайлап алына һәм үзегез сайлаган җавапның номерын А 1 дисез дә язып куясыз.***

**А 1. [ө] авазы ...**

1) урта күтәрелешле, иренләшмәгән, кыска алгы рәт сузыгы
2) урта күтәрелешле, иренләшкән, кыска алгы рәт сузыгы
3) югары күтәрелешле, иренләшмәгән, кыска алгы рәт сузыгы
4) түбән күтәрелешле, иренләшкән, арткы рәт сузыгы

**А 2. Кайсы рәттәге барлык сүзләрнең әйтелеше белән язылышы туры килә?**

1) буяу, каләм, мөлкәт, оҗмах
2) урман, ураза, чыбык, җитен, сүрән
3) суккалау, вәгъдә, урам, тәүлек
4) намус, нәсел, саулык, гомер

**А 3. Кайсы рәттәге сүзләрнең барысында да бишәр аваз бар?**

1) буяу, илһам, ишарә, елан, ерак
2) япма, япьле, төзәю, оятлы
3) хәбәр, хәер, сөенү, сәхнә
4) хәвеф, тоелу, сазлык, оялу

**А 4. *Ялгызлыгымнан* сүзенең мәгънәле кисәкләргә дөрес бүленешен күрсәтегез.**

1) ял-гыз-лы-гым-нан
2) ял-гызлык-ы-м-нан
3) ял-гыз-лык-ы-м-нан
4) ялгыз-лык-ым-нан

**А 5. *Көннәрне үткәрү* сүзтезмәсендә компонентларны үзара бәйләүче чараны күрсәтегез.**

1) янәшә тору
2) күплек сан кушымчасы
3) килеш кушымчасы
4) күплек сан һәм килеш кушымчасы

**А 6. Кайсы рәттәге җөмләдә, фигыльне ачыклап, эшнең үтәлешенә бәйле объектка күрсәткән иярчен кисәк юнәлеш килешендәге исем белән белдерелгән?**

1) Тормыш бераз эзгә төште. *(Ф. Яруллин)*
2) Авыл халкы озатырга чыкты. *(Г.әәширов)*
3) Нуриәсма гомере буе таңга, кояшка, җиргә табынды. *(Ф. Садриев )*
4) Алар хәзер ят яңа җирләргә барып җитәргә ашыга. *(Н. Фәттах )*

**А 7. Җөмләдә ничә компонент бар, алар үзара ничек бәйләнгән? Җөмләнең төрен билгеләгез.**

***Эчтән, бөркелеп-бөркелеп, әче төтен чыга, пар күтәрелә, тик ялкын инде күренми.*** *(С. Шәмси)*

1) өч, санау интонациясе һәм тезүче теркәгеч ярдәмендә бәйләнгәннәр, бу — күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә
2) ике, санау интонациясе ярдәмендә бәйләнгәннәр, бу — теркәгечсез тезмә кушма җөмлә
3) ике, каршы куючы теркәгеч ярдәмендә бәйләнгәннәр, бу — теркәгечле тезмә кушма җөмлә
4) өч, санау һәм каршы кую интонациясе ярдәмендә бәйләнгәннәр, бу — күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә

**А 8. Ия ул — ...**

1) җөмләнең башка сүзгә буйсынмаган баш килештәге кисәге
2) җөмләнең баш килештәге сүз турында хәбәр итә яки үзе генә дә хәбәрлекне белдерә ала торган баш кисәге

3) җөмләнең бары тик хәбәренә генә буйсына торган кисәге
4) җөмләдә исем сүз төркеме белән генә белдерелә торган кисәк

**А 9.** ***Элек кигән күлмәкләрем сакланмаган.*** *(Н. Измайлова)* **Бу җөмләдәге *кигән* сүзе җөмләнең кайсы кисәге?**

1) хикәя фигыль
2) сыйфат фигыль
3) аергыч
4) хәбәр

**А 10. Тыныш билгесе кайсы очракта дөрес куелган? *Бушап калган иген басулары (1) Җырлар тынган (2)сүнгән учаклар (3)*** *(Р. Низами)*

1) (1) өтер, (2) нокталы өтер, (3) нокта
2) (1) өтер, (2) сызык, (3) нокта
3) (1) сызык, (2) өтер, (3) нокта
4) (1) өтер, (2) өтер, (3) нокта

**А 11. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләр җөмләнең кайсы кисәге икәнен күрсәтегез.**

*Минем **курку** чиктән ашкан. (М. Гафури)*

1) ия
2) хәбәр
3) аергыч
4) хәл

**А 12. Бирелгән өзек нинди стильдә язылган?**

(1) Бер башлангач, гомер ага да ага икән ул. (2) Гомер агышын туктатыр бер генә көч - кодрәт тә юк бу дөньяда.
(3) Гомер, сыналып килеп, мәңгегә сынар өчен, бер бирелә.
(4) Җәйне көзнең сары яфраклары каплый, көзне — кышның ак карлары, кышны — язгы сулар, ташулар. (5) Адәм баласы менә шулай дүрт фасыл эчендә бәргәләнә. (6) Аның өчен бишенче фасыл юк. (7) Бу фасыл, бәлки, мәңгелек булыр иде. (8) Бишенче фасыл — үлем.

1) матур әдәбият стилендә
2) публицистик стильдә
3) рәсми стильдә
4) фәнни стильдә

## 2 нче өлеш - В

***Бу өлештәге биремнәрне үтәгәндә, сорау янына ничә сан куела, җаваплар шул хәтле булырга тиеш. Санны куясыз да, аннан соң җавапларны язасыз.***

7. Нинди сүзлекләр була (1, 2)
8. Татар теленең төп диалектлары (1, 2, 3)
9. Татар әдәби теленең төп стильләре (1, 2, 3,4, 5)
10. Грамматика нинди өлешләрдән тора (1, 2, 3)
11. Исем нәрсәләр белән төрләнә (1, 2, 3)
12. Саннарның төркемчәләрен язарга (1, 2, 3, 4, 5)

## 3 нче өлеш – С 1

***Текстны укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.***

1) Урманда чикләвек җыйган чак искә төшә. 2) Олы – олы керфекләрен ачып – йомып утырган кишәнкеләрне, берәм – берәм, капчыгыңа тутырасың. 3) Зурлыгы имән чикләвегеннән кайтыш, ләкин бик тә чибәр һәм йомры “күчтәнәч”ләр магнит сыман гел үзенә тартып тора. 4) Куак арты куакны сыгып төшерәсең. 5) Дүрт чикләвекле... бишле... алтылы... Һәм менә шулчак кемдер: “Миндә сигезле!” – дип тирә – юньгә өн сала икән, ул дустыңа сокланып та, бераз көнләшеп тә карыйсың. 6) Әйе, беренче булуның үз ләззәте, үз рәхәте бар. 7) Әдәбиятта да

шулайрак түгелме соң? 8) Беренче булып яңа сүз әйтәсе, яңа ачышлар ясыйсы, образлар тудырасы килә.

1) 5 нче җөмләдән парлы сүзне күчереп язгыгыз.
2) Өченче абзацтан фразеологик әйтелмәне табып, күчереп языгыз.
3) 6 – 8 нче җөмләләрдән синонимнарны табып языгыз.
4) Тексттан мәкаль булган җөмләне табып, санын күрсәтегез.
5) 1 – 4 җөмләләрдән сыйфатлар булган җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә күрсәтегез.

**3 нче өлеш – С 2**

"Минем киләчәк һөнәрем" дигән темага миниатюр сочинение язарга.

***Җаваплар:***

**1 нче өлеш**

| | |
|---|---|
| А 1 | 2 |
| А 2 | 2 |
| А 3 | 1 |
| А 4 | 4 |
| А 5 | 3 |
| А 6 | 3 |
| А 7 | 1 |
| А 8 | 1 |
| А 9 | 3 |
| А 10 | 4 |
| А 11 | 1 |
| А 12 | 1 |

**2 нче өлеш**

1. Нинди сүзлекләр була (аңлатмалы, телара)
2. Татар теленең төп диалектлары (урта, көнбатыш, көнчыгыш)
3. Татар әдәби теленең төп стильләре (әдәби, публицистик, фәнни, рәсми, сөйләмә)
4. Грамматика нинди өлешләрдән тора (морфология, синтаксис, сүз ясалышы)
5. Исем нәрсәләр белән төрләнә (сан, килеш, тартым)
6. Саннарның төркемчәләрен язарга (микъдар, тәртип, җыю, бүлем, чама)

**3 нче өлеш**

1. Тирә – юньгә
2. Буш сүз очыру
3. Ләззәте, рәхәте
4. 13
5. 2, 3

## Студентларның татар теленнән белемнәрен тикшерү өчен тестлар

**Исем**

1 Исем нәрсәне белдерә?

1. Предметның исәбен
2. Предметның билгесен
3. Эш яки хәлнең билгесен

4. Предмет исемен һәм затын

2 Исем нинди сорауларга җавап бирә.

1. Кайда?, кайчан?, Ничек?
2. Кем ?, нәрсә? ни?
3. Нинди кайсы, кайдагы?
4. Нишли, нишләгән, нишләр.

3 Исем нәрсәләр белән төрләнә.

1. Зат-сан белән, өч заманда килә
2. Берни белән дә төрләнми
3. Бары тик килеш белән
4. Тартым, килеш, сан белән

***4 Кызым,*** *синең* ***эшең*** *бик күп.*

1. Ия, тәмамлык
2. Эндәш сүз, ия
3. Ия, аергыч
4. Эндәш сүз, аергыч

*5 Икесе дә -безнең өчен*
*Иң кирәкле затлы тел.( бу җөмләдә исем нинди җөмлә кисәге була)*

1. Ия
2. хәбәр
3. тәмамлык
4. аергыч

6 Ясалышы ягыннан болар нинди исемнәр***. Басма, башкала***

1. ясалма, саф кушма
2. сафкушма
3. ясалма
4. тамыр һәм ясалма

7 Кайсы сүз төркемендә ясалышы ягыннан барлык сүз төрләре дә очрый

1. Фигыльдә
2. сыйфатта
3. рәвештә
4. исемдә.

**Сыйфат**

1Сыйфат  нәрсәне белдерә?

1. Предметның исәбен
2. Предметның билгесен
3. Эш яки хәлнең билгесен
4. Предмет исемен һәм затын

2 Исем нинди сорауларга җавап бирә.

1. Кайда?, кайчан?, Ничек?
2. Кем ?, нәрсә? ни?
3. Нинди, кайсы, кайдагы?
4. Нишли, нишләгән, нишләр.

3 Сыйфатларны тап
1. Иркенчәк, үткен
2. Язучы, киләчәк
3. Үткәр ,язган
4. Укучы, тырышкан

*4 Ясалышы ягыннан болар нинди сыйфатлар*
*1 Аксыл сары*　　　　*2 кара коңгырт*
1. Саф кушма
2. ясалма
3. тезмә
4. парлы

5 Түбәндәге мисалда калын хәрефләр белән бирелгән сыйфатлар нинди җөмлә кисәге була.
- *И, Куян, куркан Куян. йомшак Куян,*
*Моңланасың нинди хәсрәт, кайгыдан.*
1. аергычлар
2. аергыч, хәбәр
3. ия, аергыч
4. тәмамлык аергыч

6 Ясалышы ягыннан болар нинди сыйфатлар ***. Җилбәзәк, җилкуар***
5. ясалма, сафкушма
6. сафкушма
7. ясалма
8. тамыр һәм ясалма

7 Монда нинди сыйфатлар
*Ялгыз-- күмәк, батыр- куркак*
1. синоним сыйфатлар.
2. омоним сыйфатлар.
3. антоним сыйфатлар.

8 Синоним парын табыгыз ***Пөхтә***
1. ыспай, чиста
2. чиста, саф
3. көяз, купшы
4. чиста, шапшак

9 Сыйфатларның үзләренә генә хас нинди грамматик категориясе бар.
1. килеш белән төрләнми
2. тартым белән төрләнми
3. сыйфатланмышы урынында исем кебек төрләнү.
4. сыйфат дәрәҗәсе

10 Артыклык дәрәҗәсен ясаучы нинди кисәкләр сызыкча аша ясала.
1. Сыйфатның беренче иҗеге белән бернинди уртаклыгы булмаган
2. Сыйфатның беренче иҗеге белән бернинди уртаклыгы булган
3. Чалт, чатнама, тома, шыр, иң

4. Ямь, кып, ап, шыр, тома.

**Сан**

1Сан   нәрсәне белдерә?

1. Предметның исәбен
2. Предметның билгесен
3. Эш яки хәлнең билгесен
4. Предмет исемен һәм затын

2 Бу мисалда саннар җөмләнең нинди кисәге булып килә.

***Икесенә бер*** *зур гына капчык тегеп,*
*Китте болар кырга таба сәфәр чыгып*

1. Ия, аергыч
2. ике аергыч
3. тәмамлык белән хәл
4. тәмамлык, аергыч

3 Ясалышы ягыннан болар нинди саннар. ***Җиде- сигез, илле- алтмыш, бер- ике.***

1. тамыр
2. саф кушма
3. парлы
4. тезмә

4 Сан төркемчәсе буларак, болар нинди саннар.

***унике, егерме сигез, ярты, биш йөз***

1. төп
2. тәртип
3. җыю
4. күләм- чама

5 Бу саннар нинди орфографик принципка нигезләнеп языла

***Унөч, унбиш, уналты***

1. фонетик
2. тарихи- традицион
3. график
4. морфологик

6 Бу җөмләнең иясен табыгыз

***Ак күлмәкле ике укучы килеп керде.***

1. ике укучы
2. укучы
3. ак күлмәкле укучы
4. күлмәкле ике укучы

**Рәвеш**

1 Рәвеш нинди сүз төркеме

1. Предметның  билгесен белдерүче
2. Предметның   эшен яки хәрәкәтен белдерә
3. Предметның   исәбен яки санын белдерә
4. Эш яки хәлнең , яисә билгенең билгесен белдергән сүз

2 Рәвеш нәрсә белән төрләнә
1. зат белән
2. берни белән дә төрләнми
3. сан белән
4. тартым белән

3 Рәвеш күбрәк җөмләнең  кайсы кисәге була
1. хәл
2. аергыч
3. тәмамлык
4. хәбәр

4 Хәлдән тыш, рәвеш тагын нинди җөмлә кисәге була
1. ия, тәмамлык
2. ия, хәбәр
3. хәбәр, аергыч
4. тәмамлык хәбәр

5 Кайсы сүз төркеме хәл ролендә еш килә яки рәвеш үзе кайсы сү төркеме урынында була ала.
1. исем
2. фигыль
3. сыйфат
4. алмашлык

6 Рәвешнең сорауларын күрсәтегез
1. кайда, кайчан, ничек, никадәр, күпме
2. нишли, нишләгән, нишләп, нишләү
3. күпме, ничә, ничәләп, ничәнче
4. нинди кайсы

7 Ясалышы ягыннан болар нинди рәвешләр ***юри, шунлыктан***
1. вакыт
2. охшату- чагыштыру
3. саф
4. сәбәп- максат

8 Рәвешләрне аерып күрсәтегез
1. укый-укый, бериш, шундый
2. килә- китә, шактый, җәен, берьюлы
3. җәй, берьюлы, килә-китә, шундый
4. шундый, шактый, укый- укый, бериш

**Фигыль**

1 Затланышлы фигыльләрне билгеләгез
1. Сыйфат фигыль,  хәл фигыль, исем фигыль,
2. Исем фигыль, инфинитив, шарт  фигыль,
3. Хикәя фигыль, исем фигыль, хәл фигыль,
4. боерык фигыль, хикәя фигыль, шарт фигыль,

2 Болар нинди фигыльләр ***Тырышса, кайгырса да***
1. Хикәя фигыль,
2. Шарт фигыль,

3. Боерык фигыль,
4. Билгесез үткән заман хикәя фигыльләр.

3 Фигыльләрне табыгыз . Ул нинди фигыль? Җөмләнең кайсы кисәге була.
***һич күләгә төшермә син җаныңдагы***
***Туган илең, Туган җирең яктысына***

1. Шарт фигыль, хәл
2. Хәзерге заман хикәя фигыль, хәбәр
3. боерык фигыль, хәбәр
4. үткән заман хикәя фигыль, хәбәр.

4 Монда кайсы сүзләр борык фигыльләр.
***җырлый, тырышса,укы, төзе, язар,уйнаса, яшәсен, шаярыр, шаярсы, уйнаган, омтылса да.***

1. укы , төзе, яшәсен, шаярсын
2. җырлый, язар, шаярыр, уйнаган
3. тырышса, уйнаса, омтылса, да
4. уйнаган, уйнаса, җырлый, укы.

5 Монда нинди фигыльләр.
***тырышты, эшләгән, күрдек, барганбыз***

1. Үткән заман хикәя фигыль
2. Киләчәк заман хикәя фигыль
3. Хәзерге заман хикәя фигыль
4. Шарт фигыльләр

6 Бу нинди фигыль ***Хөрмәт итәчәк.***

1. Билгесез к.з. хик ф., 3 зат берлектә барлыкта
2. Билгеле үт .з. хик ф., 3 зат берлектә барлыкта
3. Билгеле  к.з. хик ф., 3 зат берлектә барлыкта
4. Билгесез үт .з. хик ф., 3 зат берлектә барлыкта

7 Өзектән фигыльләрне тап
***Аһ итәр әле сабантуй,***
***Котлар аны киләчәк***

1. Киләчәк, аһ итәр
2. аһ итәр, киләчәк
3. аһ итәр, котлар, киләчәк
4. киләчәк, котлар

8 Затланышлы фигыльләрнең кайсысы өч заманда да була

1. шарт фигыль, боерык фигыль
2. борык фигыль, хикәя фигыль
3. боерык фигыль
4. хикәя фигыль

9 Күп нокталар урынына нинди фигыль куяр идегез.

***Су буена …… әллә нишлим-***
***кайтам кебек мин үткәнемә.***
***Чишмәләрең суын ……,***
***Куәт иңә бөтен тәнемә***

1. эчсәм, күрсәм,

2. кайтсам, эчсәм
3. кайтсам , юнәлсәм
4. эчсәм, татысам

**Фигыльләрне кабатлау**

1 Фигыль нигездә нинди җөмләкисәге була

1. Хәбәр
2. Теләсә кайсы кисәк
3. Хәл һәм аергыч
4. Ия белән хәбәр

2 Барлык фигыльләрдә дә була торган билгеләрне әйтегез

1. Өч заманда төрләнү
2. Зат белән төрләнү
3. Сан белән төрләнү
4. Барлык һәм юклык

3 Кайсы фигыльләр өч заманда да килә?

1. Хикәя һәм сыйфат фигыльләр
2. Барлык фигыльләр дә
3. Шарт, исем, сыйфат фигыльләр
4. Инфинитив, боерык һәм хикәя фигыльләр

4 Кайсы фигыльләр сан белән төрләнми

1. Исем фигыльләр
2. Хәл фигыль белән инфинитив
3. Хәл һәм шарт фигыльләр
4. Боерык фигыль белән инфинитив

5 Бу җөмләдә нинди фигыльләр бар?

*Без яшәгән авыл борыла- борыла аккан Агыйдел буена урнашкан.*

1. Өч сыйфат һәм бер хәл фигыль
2. Өч хикәя һәм бер хәл фигыль
3. Ике хикәя, берәр сыйфат һәм хәл фигыль
4. Ике сыйфат, берәр хикәя һәм хәл фигыль

6 Төзелеше ( ясалышы) ягыннан болар нинди фигыльләр

*саубуллашу, бүләк итте, җилли*

1. Тамыр, парлы, кыскартылма
2. Кушма, тезмә, ясалма
3. Ясалма, кыскартылма, тезмә
4. Кушма, парлы, тамыр

7 Болар нинди фигыльләр

*Өлгерә-җитешә,йөгергән- чапкан*

1. Омонимнар
2. Антонимнар
3. Синонимнар
4. Пралы фигыльләр

8 Кайчан сыйфат фигыль җөмләнең теләсә кайсы кисәге була

1. Сыйфатланмышы белән килгәндә
2. Сыйфатланмышы урынында килгәндә
3. Үткән заманда булганда
4. Киләчәк заманда булганда

9 Болар нинди фигыльләр
*Төйи—бушата, мактый- хурлый*
1. Омонимнар
2. Антонимнар
3. Синонимнар
4. Пралы фигыльләр

10 Бу фигыльләр кайсы төркемчәгә карый?
1. Хәл фигыль
2. Шарт фигыль
3. Хикәя фигыль
4. Инфинитив

11Фигыльнең башлангыч формасы дип нәрсәгә әйтәләр
1. Боерык фигыль
2. 2 зат хәзерге заман хикәя фигыльнең берлеге
3. Фигыльнең тамыр, ясалма, яки тезмә нигезе
4. Тамыр яки ясалма боерык фигыльнең 2 зат берлеге

12 Фигыль төркемчәләре ничек ясала
1. Исемгә төр ясагыч кушымчалар кушылып
2. фигыльнең башлангыч формасына төр ясаучы кушымчалар ялганып
3. сыйфатка төр ясагыч кушымчалар кушылып
4. Фигыльгә төр ясагыч кушымчалар кушылып

## Татар теленнән контроль эш биремнәре

**1. Сүзтезмәләрне тәрҗемә итегез һәм һәр сүзне антонимы белән алыштырыгыз.** (Һәр дөрес җавапка 1 әр балл)

*Возвращение из юга –*
*Хороший сон –*
*Прощание с прошлым –*
*Доброе начало –*
*Добрая мама –*

**2. Гади һәм кушма җөмләләрнең уртак һәм аермалы якларын санап чыгыгыз.**

**3. *Аяклар талды — аны сизмәдек (А. Гыйләҗев)* җөмләсе** (1 балл)

1) гади җөмлә;
2) тезмә кушма җөмлә;
3) иярченле кушма җөмлә булып килә.

**4. Борһан ага эшне шундый итеп оештырды ки, безнең бер минутыбыз да бушка узмый. (Р.Төхфәтуллин).** (1 балл)

1) иярчен аергыч җөмлә;
2)иярчен максат җөмлә;
3)иярчен рәвеш җөмлә.

**5. Текстны укыгыз. Биремнәрне үтәгез. (20 балл)**

1) Хәсән Туфан үзенең иҗатында яхшылыкка, мәрхәмәтле булырга өндәп килде. 2) Ул шәхси тормышында да гомер буе кешегә яхшылык кылып, игелекле, иркен күңелле кеше булып яшәде. 3) Бу шагыйрьнең балалар белән дуслыгында бигрәк тә ачык күренә иде. 4) Кешенең

кемлеген, аның холкы-фигыле ниндилеген, ихтимал, балалардан да тирәнрәк, алардан да тизрәк сизеп алучы булмыйдыр. 5) Хәсән Туфан аларның “телен” белгәнгәдерме, якты чырае, ягымлы мөнәсәбәте белән мәхәббәтләрен казангангадырмы, әмма ул Аккош күлендәге иҗат дачасында балаларның иң якын дусларына әверелер иде. (Г. Бәширов)

1. 1-3 нче җөмләләрдән *ясагыч кушымча ялгану ысулы* белән ясалган *исемнәрне* язып алыгыз.
2. 3-5 нче җөмләләрдән *кереш сүзне* табып языгыз.
3. *Рәвешләрне* табыгыз һәм төркемчәләрен билгеләгез.
4. Исемләшкән *хәзерге заман сыйфат фигыльне* табып языгыз.
5. Күренекле татар шагыйре Хәсән Туфан турында белгәннәрегезне 6 җөмлә күләмендә хикәя итеп языгыз.

**6. Саннар кергән 3 мәкаль-әйтем языгыз.(3 балл)**

**7. Җөмләләрдәге билгеләнгән сүзләрнең кайсы сүз төркемнәренә керүен күрсәтегез. *Баштанаяк* сүзенә морфологик анализ ясагыз. (6 балл)**

***Чана*** *шуганда, Фирүзәнең елап торганын* ***күрде*** *Илгиз. Күрде* ***дә*** *юату нияте* ***белән баштанаяк*** *карга буялган Фирүзәгә* ***якынрак*** *елышты. (Ф. Шәфигуллин)*

**8. Җөмләне укыгыз. Тыныш билгеләрен куегыз. Җөмләнең төрен билгеләгез. (7 балл)**

Тәрәзәдән карап утыра торгач үзе өчен кызыклы бер яңалыкны ачты Илгиз агач ботагындагы бияләйгә бала-чагалар кызлар егетләр һәм эти кешеләр бөтенләй диярлек игътибар итмиләр. *(Ф. Шәфигуллин)*

## **Һөнәри эшчәнлектә татар теле фәненнән контроль эш өчен тестлар** (2 төр)

1) Сөйләмнең төп берәмлекләрен санарга. (Сүз, җөмлә, текст).
2) Сөйләм ситуациясендә сөйләм элементлары. (Сөйләүче, тыңлаучы, сөйләмнең темасы, вакыты, урыны, максаты, сәбәбе).
3) Сөйләм төрләре. (Телдән сөйләү һәм язма сөйләм).
4) Сөйләм техникасының төрләре. (Сулыш алу, тавыш, дикция, интонация).
5) Сөйләм үзенчәлекләре. Хәбәрлек һәм модальлек).
6) Сөйләмнең функциональ стильләре. (Әдәби, публицистика, фәнни, рәсми, сөйләмә).
7) Рецензия нәрсә ул? (Рецензия – әдәби тәнкыйтьнең бер төре. Матур әдәбият китабын, картинаны, спектакльне, кинофильмны һ.б. кыскача гына бәяләгән әдәби тәнкыйть әсәре).
8) Аннотация нәрсә ул? (Аннотация – латин сүзе, кечкенә мәкалә дигәнне аңлата. Китапның кыскача эчтәлеген бирүче кечкенә мәкалә, эчтәлекне кыскача язып аңлату).
9) Публицистик стиль – программист һөнәре турында мәкалә язарга.
10) Чыгыш нинди өлешләрдән тора. (Кереш, төп, йомгак).
11) Әңгәмә коруның ике моделе. ( “Ачык” сөйләм һәм “ябык” сөйләм).
12) Сүзлек төрләре. (Телара, аңлатмалы).
13) Сөйләм культурасына төп таләпләр. (Сөйләм аңлаешлы, саф, аһәңле, төгәл, җыйнак булырга тиеш).
14) Сүзнең мәгънәләре. (Туры һәм күчерелмә).
15) Татар телендә алынма сүзләр кайсы телләрдән кергән? (Гарәп- фарсы, рус, европа телләреннән).
16) Искергән сүзләр. (Тарихи сүзләр һәм архаизмнар).
17) Татар теленең диалектлары. (Урта, көнчыгыш, көнбатыш).
18) Сөйләмнең сәнгатьчә сурәтләү алымнары. (Эпитет, чагыштыру, метафоралар, метонимия, сынландыру, арттыру, антитеза, оксюморон, литота һ.б.).

Контроль диктантлар: М. Мәһдиевнең “Бәхилләшү”әсәреннән өзек
Контроль изложениеләр: “Әбиемнең куллары”, “Кыр казы”
Контроль сочинение: “Программист һөнәренең мөһимлеге”

## Кулланылган әдәбият

**Төп китаплар:**

- Зәкиев М. З., Максимов Н. В. Татар теле. 10-11 сыйныфлар өчен дәреслек.-Казан: Мәгариф, 2008;
- Р. К. Сәгъдиева. Татар теле. 10 нчы сыйныф өчен дәреслек. -Казан. “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты. 2017;
- Р. К. Сәгъдиева. Татар теле. 11 нче сыйныф өчен дәреслек. -Казан. “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты. 2017;
- Диктантлар җыентыгы – 10 – 11 сыйныфлар өчен
- Изложениеләр җыентыгы 10 – 11 сыйныфлар өчен
- Сочинениеләр җыентыгы 10 – 11 сыйныфлар өчен

**Өстәмә китаплар:**

Күнегүләр. Анализ үрнәкләре. Тестлар. Татар теле. Р. Р. Шәмсетдинова,

Татар теленнән кагыйдәләр җыентыгы. “Гыйлем” нәшрияты. – 2008.

**Интернет – ресурслар:**

http://tatar.com.ru/ все для изучения татарского языка

http://kitap.net.ru/ татарская электронная библиотека

http:/www. Kitaphane.tatar.ru Национальная библиотека Республики Татарстан

http://tatar.info/ проект свободной многоязычной энциклопедии о татарской нации, её культуре, языке, истории и традициям

# II КУРС УКУЧЫЛАРЫНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕННӘН БЕЛЕМНӘРЕН БӘЯЛӘҮ

## ЯЗМА ЭШЛӘР

Туган тел буенча бирелгән белемнәрнең үзләштерелү дәрәҗәсен, язуда дөрес кулланылышын тикшерү максатыннан татар теле дәресләрендә төрле язма эшләр — диктант, изложение һәм сочинениеләр яздырыла. Диктантларны бәяләгәндә, орфографик һәм пунктуацион хаталарның саны, ә изложение белән сочинениеләрдә исә, орфографик һәм пунктуацион хаталар белән бергә, теманың ачылу дәрәҗәсе, язманың тел байлыгы (С), грамматик ялгышлары (Г.), логик (Л.) һәм фактик (Ф.) хаталар да исәпкә алына.

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1.<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>2. | Шул сыйныфка таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиз, ачык, дөрес әйтелеп, фикер аңлаешлы бирелсә, ягъни:<br>— фонетик үзенчәлекләр (хәрефләрнең укылыш үзенчәлекләре) дөрес бирелсә;<br>— татар әдәби теленең орфоэпик нормалары (сүзнең язылыш һәм әйтелеш үзенчәлекләре) сакланса;<br>— җөмләләр сөйләмнең төп структур берәмлекләренә (сүзләр — иҗекләргә; җөмлә — сүз тезмәләре һәм сүзләргә, мәгънәле кисәкләргә) дөрес бүленсә;<br>— тукталышлар (паузалар) дөрес ясалса, сүз басымы һәм логик басым дөрес укылса яисә куелса;<br>— интонацион яктан тексттагы җөмләләр дөрес тавыш белән укылса;<br>Укытучының текст эчтәлегеннән чыгып бирелгән сорауларына төгәл җавап бирелсә; | «5»ле билгесе куела. |
| 1.<br><br><br><br><br><br><br><br><br>2. | Таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиешле тизлектә укылса, ләкин кайбер сүзләрнең әйтелешендә фонетик, орфэпик үзенчәлекләр тиешенчә үтәлмәсә ягъни:<br>— кайбер сүзләрне укыганда, сүзләрнең укылыш үзенчәлекләре орфоэпик нормаларга туры килмәсә;<br>— сөйләмнең структур бүленешендә кайбер хаталар булса;<br>— җөмләне укыганда, интонацион яктан 1-2 төгәлсезлек җибәрелсә;<br>Укытучының сорауларына төгәл җавап бирелсә; | «4» ле билгесе куела. |
| 1.<br><br>2.<br><br>3. | Уку тизлеге вакыт чикләренә сыймаса һәм уку барышында 3-4 фонетик, 2-3 орфоэпик хата җибәрелсә;<br>Текст сөйләм берәмлекләренә тиешенчә бүленмәү сәбәпле, интонация төгәл бирелмәсә;<br>Текстны аңлап та, сорауларга бирелгән җавапларда төгәлсезлекләр булса; | «3»ле билгесе куела. |
| 1.<br>2.<br><br>3.<br><br>4. | Тиешле тизлектә уку күнекмәләре булмаса;<br>Уку барышында үтелгән орфограммаларда төгәлсезлекләр күп кабатланса;<br>Уку барышында җибәрелгән фонетик, орфоэпик, интонацион хаталар текст эчтәлеген аңлауга комачауласа;<br>Текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга өлешчә генә җавап | «2» ле билгесе куела. |

| | | |
|---|---|---|
| | алынганда; | |

Язма эшләрдә җибәрелгән хаталар тупас һәм тупас булмаган хаталарга бүленеп йөртелә.

Тупас хаталарга алдагы сыйныфларда һәм бу уку елында үтелгән орфографик, грамматик һәм пунктуацион кагыйдәләргә караган хаталар керә.

Тупас булмаган орфографик хаталар:

— укучы үзе төзәткән орфографик хаталар (өч хатасын үзе төзәткән укучының эше бер баллга түбән бәяләнә); язылышы татар теле кагыйдәләренә туры килмәгән ялгышлар (Акъегет, көньяк, төньяк, Сибгат һ. б.); мәгънәләре төрлечә кулланылган кушма яки тезмә сүзләрне бутап язу (аш казаны — ашказаны, бер үк — берүк, кай вакыт — кайвакыт, ике йөзле — икейөзле, ил гизәр — Илгизәр, өй алды — өйалды һ. б.);

— программа нигезендә өйрәнү күздә тотылмаган яки соңрак үтеләчәк теоретик материалларга караган орфографик хаталар;

— беренче тапкыр очраган алынма сүзләрне, шулай ук тар профессиягә караган атамаларны язудагы хаталар;

— дәреслектә күрсәтелмәгән очракларга караган сүзне юлдан юлга күчерүдә ялгышу.

Тупас булмаган пунктуацион хаталарга җөмлә эчендәге синтагмаларны яки кушма җөмлә өлешләрен аеру өчен, функцияләре бердәй булган тыныш билгеләренең берсе урынына икенчесен кую (теркәгечләрдән башка бәйләнгән ике тиңдәш кисәкнең берсе икенчесенә каршы куюны белдергән очракта сызык яки өтер кую; гомумиләштерүче сүзләр янында — ике нокта яки сызык; аныклагычлар янына — сызык, ике нокта, җәяләр яки ике яктан өтер; ымлык яки аваз ияр-темнәреннән соң — өтер яки өндәү билгесе; теркәгечсез тезмә кушма җөмләдә — өтер, нокталы өтер яки сызык; тиңдәш кисәкләр арасында — өтер яки нокталы өтер; иярченле кушма җөмләдә — өтер яки ике нокта; туры сөйләм янында — сызык, өтер яки сызык, күп нокта һәм сызык, ике нокта һәм сызык; тиңдәш түгел аергычлар арасына өтер кую; берничә тыныш билгесе бергә очрашкан урыннарда ялгышу; үзара бик тыгыз бәйләнештәге гади җөмлаләрне өтер, сызык яки ике нокта белән аерып язу; тезмә кушма җөмләләрнең өлешләрен нокта белән аерып, шул фикерне гади җөмләләр итеп бирү) керә.

Контроль диктантларны бәяләү.

Бәяләү нормалары контроль диктант күләменнән чыгып бирелә. Язма эшләрнең күләме кимрәк яки артыграк булганда, нормалар да шуңа мөнәсәбәттә кими яки арта.

Сыйныфлар буенча контроль диктант күләме түбәндәгечә билгеләнә:

| Группалар | Сүзләр саны | |
|---|---|---|
| | уку елы башында | уку елы ахырында |
| I курслар | 150 | 160 |
| II курслар | 160 | 170 |

**Югарыда саналганнардан чыгып, контроль диктантлар түбәндәгечә бәяләнә:**

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1. | Орфографик һәм пунктуацион хаталар булмаган эшкә.<br>**Искәрмә.** Орфографик (яки пунктуацион) хаталы пөхтә башкарылган эшкә яки бер үк хата бер үк сүзләрдә кабатланса һәм пунктуацион бер хаталы эшкә | «5»ле билгесе куела. «5» ле билгесе куела ала. |

| | | |
|---|---|---|
| 2. | 1 орфографик, 1 пунктуацион хатасы булган эшкә<br>**Искәрмә.** 1 орфографик, 2 пунктуацион хаталы эшкә яки орфографик хаталары булмыйча, 3 пунктуацион хатасы булган эшкә, яки бер төрдәге 2 орфографик һәм 1 пунктуацион хаталы эшкә | «4» ле билгесе куела. «4» ле билгесе куела. |
| 3. | 2 орфографик, 1—3 пунктуацион хаталы, 2 төзәтүле эшкә<br>**Искәрмә.** 4 пунктуацион. 1 орфографик хаталы эшкә яки бер төрдәге 5 орфографик, 4 пунктуацион хаталы эшкә | «3» ле билгесе куела. «3»ле билгесе куела. |
| 4. | 5 орфографик, 5 пунктуацион хаталы, 4 төзәтүле эшкә | «2»ле билгесе куела. |

**Изложениеләрне бәяләү**

Изложение язу өчен, гадәттә, укучыга аңлаешлы телдә язылган хикәяләү характерындагы текст яки өзек алына. Ул матур яки фәнни-популяр әдәбияттан, көндәлек матбугаттан һ. б. алынырга мөмкин.

Нинди генә өзек яисә текст бирелсә дә, укучы аның язылу стиленә игътибар итәргә, стильләрне бутамаска тиеш. Текстның стиль үзенчәлекләре укучының язмасында да сакланырга тиеш.

Изложениенең күләме һәм эчтәлеге, сыйныфның әзерлегенә карап, укытучы тарафыннан сайлап алына.

Изложение өчен матур әдәбият һәм фольклор әсәрләреннән, вакытлы матбугаттан хикәяләү характерындагы өзекләр яки текст алына. Тезмә әсәрләр нигезендә изложение сирәк яздырыла.

Сайланган текстлар укучыларга белем һәм тәрбия бирү максатларын канәгатьләндерерлек, эчтәлеге һәм теле ягыннан аңлаешлы булырга, бәйләнешле сөйләм үстерү юнәлешендә алып барылырга тиеш.

Текст белән эшләү барышында укучыларның бәйләнешле фикер йөртә белү сәләте генә түгел, ана теленең орфографик, грамматик, стилистик һәм пунктуацион үзенчәлекләрен белүләренә, текст эчтәлегеннән чыгып, нәтиҗә ясый белү сәләтенә, сүз байлыгыннан файдалана белү мөмкинлекләренә дә бәя бирелә.

**Изложение түбәндәгечә бәяләнә:**

| № | Текстның бирелеше | Грамоталылыгы | Билге |
|---|---|---|---|
| 1. | Текст, планга нигезләнеп (яки плансыз), эзлекле бирелгән; стиль бердәмлеге сакланган; фактик һәм техник хаталар юк. | 1 орфографик яки пунктуацион (яки грамматик) хата бар. | «5» ле билгесе |
| 2. | Тексттагы хикәяләү агышы бирелгән эзлеклелек белән тулысынча туры килми; стиль бердәмлегендә хилафлык сизелә; язмада 1 фактик, 1 техник хата җибәрелгән. | 2 орфографик, 1 пунктуацион (яки 1 грамматик) хата бар. | «4» ле билгесе куела. |
| 3. | Текст язмада эзлекле бирелмәгән, стиль бердәмлеге сакланмаган. Сүзләр бәйләнешендәге төгәлсезлекләр җөмләнең мәгънәсен бозуга китергән. Язмада 1 фактик, 2 техник хата җибәрелгән. | 3 орфографик, 2 пунктуацион,1 грамматик хата бар. | «3» ле билгесе куела. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | Тексттагы эзлеклелек язмада сакланмаган; стиль бердәмлеге юк; сүзләр һәм җөмләләр бәйләнешендә хаталар бар; фактик һәм техник хаталар күп. | орфографик хата-ларның саны өчтән, пунктуацион хаталарның саны икедән, грамматик хаталарның саны өчтән артык | «2» ле билгесе куела. |

**Сочинение түбәндәгечә бәяләнә:**

| № | Эшнен эчтәлеге һәм теле | Грамоталылыгы | Билге |
|---|---|---|---|
| 1. | Эчтәлек темага туры килә; язмада фактик ялгышлар юк; план буенча (яки плансыз) эзлекле язылган; теле бай, образлы; стиль бердәмлеге сакланган. | 1 орфографик (пунктуацион яисә грамматик) ялгыш бар | «5» ле билгесе куела. |
| 2. | Язманың эчтәлеге темага нигездә туры килә, ул дөрес ачылган; 1 фактик хата җибәрелгән, хикәяләү эзлеклелегендә артык әһәмияте булмаган бозу сизелә; тулаем алганда, теле бай, образлы; стиль, бердәмлеге сакланган. | 2 орфографик, 2 пунктуацион һәм 2 грамматик ялгыш бар. | «4» ле билгесе куела. |
| 3. | Эчтәлекне бирүдә мөһим читләшүләр бар: ул нигездә дөрес, ләкин фактик төгәлсезлекләр очрый, хикәяләү эзлекле түгел; теленең ярлылыгы сизелеп тора; синонимик сүзләрне аз куллана, бертөрлерәк синтаксик төзелмәләр файдалана, образлы түгел, сүз куллануда ялгышлар җибәрә; стиль бердәмлеге сакланып җитмәгән. | 3 орфографик, 3 пунктуацион һәм 3 грамматик ялгыш бар. | «3»ле билгесе куела. |
| 4. | Тема ачылмаган; фактик төгәлсезлекләр күп; планга туры килми, эзлеклелек бозылган; теле ярлы; сүз куллану ялгышлары еш очрый; стиль бердәмлеге юк. | 7 орфографик, 7 пунктуацион һәм грамматик ялгышлар бар. | «2» ле билгесе куела. |

Язма эштән соң беренче юлга, кызыл юл турысыннан башлап, ялгышларның саны күрсәтелә: башта орфографик, аннан соң пунктуацион һәм стилистик хаталар саны языла. Аларны ике нокта аша күрсәтергә була: 1:3:2. Бу язылыш 1 орфографик, 3 пунктуацион, 2 стиль хатасы барлыкны аңлата.